ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№361 от «08» 11 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның 19 октябрендәге
№ 348 карарына үзгәрешләр
кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына 3 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында 916 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **к а р а р б и р ә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 октябрендәге «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында 348 нче карары белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 36 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 абзац өстәргә:

- «Сатып алына торган (шул исәптән өлешле төзелеш объекты булып торган) торак урын яки торак йорт төзелеше Татарстан Республикасы территориясендә булырга яки гамәлгә ашырылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов